РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

Буа шәһәре

**КАРАР**

05.02.2026

№ 26/Бк/к

Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчесе һәм җитәкчеләре вазыйфасына кандидатларга аттестация уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 01 апрелендәге 81/Бк/к номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясы, «Россия Федерациясендә Архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, мәгариф оешмалары җитәкчеләрен аттестацияләү тәртибен камилләштерү максатларында Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчесе һәм җитәкчеләре вазыйфасына кандидатларга аттестация уздыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 01 апрелендәге 81/Бк/к номерлы карарына, «аттестация үткәрүне методик һәм оештыру-техник тәэмин итү» IV бүлеген түбәндәге эчтәлекле 4.4 пункт белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«4.4. Муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчесе һәм җитәкчеләре вазыйфасына кандидатларны аттестацияләү барышында төзелгән документлар (аттестация комиссиясе утырышларының гаризалары, тәкъдимнәре, беркетмәләре, идарә проектлары, комиссия карарлары) аттестация процедурасы тәмамланган көннән алып 5 ел дәвамында «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе архивында сакланырга тиеш. Күрсәтелгән срок тәмамлангач, документлар, Россия Федерациясенең архив эше турындагы законнары таләпләре

нигезендә, билгеләнгән тәртиптә юкка чыгарылырга йә Буа муниципаль районы Башкарма комитеты архивына тапшырылырга тиеш.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары – «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Н.А.Македонскаяга йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов